БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 октября 2022 ел № 144

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренен вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елнын 1 ноябрендәге 152 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 11 номерлы, 2022 елнын 18 гыйнварендәге 101 номерлы, 2022 елнын 25 февралендәге 109 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Татарстан Республикасында берәмлекләр башлыкларынын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары депутатларынын, әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларынын, аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларынын, сайланулы вазыйфаи затларынын, муниципаль берәмлекләрнен контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнен хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы үзгәрешләр белән һәм Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренен вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы

карарына (алга таба - Карар) 2018 елның 1 ноябрендәге 152 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 11 номерлы, 2022 елның 18 гыйнварендәге 101 номерлы, 2022 елның 25 февралендәге 109 үзгәрешләр белән түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктының 2 пунктчасында «11498» санын «11 958» санына, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан «12 688» санына алмаштырырга;

1.2. Караның 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «30442» санын «31660» санына, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан «33592» санына алмаштырырга;

- «27398» санын «28494» санына, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан «30233» санына алмаштырырга;

1.3. Карарның 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «18748» санын «19498» санына, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан «20688» санына алмаштырырга;

- «13968» санын «14527» санына, ә 2023 елнын 1 гыйнварыннан «15414» санына алмаштырырга;

1.4. Карарның 3 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «17253» санын «17944» санына, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан «19039» санына алмаштырырга;

- «15759» санын «16390» санына, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан «17390» санына алмаштырырга.

1.5. Карарның 10 нчы кушымтасына «1 процент» сүзен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру тәртибенең 8 пунктын (20 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Балтач шәһәр җирлеге башлыгына айлык акчалата бүләкләү өлешендә хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме - елга 11,34 айлык акчалата бүләкләү, хезмәт өчен түләүнең 11 төркеменә кертелгән Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына - елга 10,36 айлык акчалата бүләкләү, хезмәт өчен түләүнең 12 төркеменә кертелгән Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына - елга 9,26 айлык акчалата бүләкләү, Балтач шәһәр җирлеге башлыгы урынбасарына - 10,69;

1.7. Караның 20 нче кушымтасының 14 пунктындагы 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарның 1.1.-1.4 пунктларында кертелгән үзгәрешләр имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның 1.5-1.7 пунктларында кертелгән үзгәрешләр 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р. Нотфуллин